УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан шәһәре**

30 гыйнвар, 2023 ел № 5

Апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә боерык бирәм:

1. Апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.
2. Хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенә боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» 2016 елның 28 сентябрендәге 62 номерлы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июнендәге 35 номерлы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 24 октябрендәге 85 номерлы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 сентябрендәге 44 номерлы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 69 номерлы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» 2022 елның 22 ноябрендәге 46 номерлы.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Идарә җитәкчесе Г.Р.Нигъмәтуллина

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты ГХАТ
идарәсенең 2023 елның «30»
01.2023 № 5 боерыгы белән
расланды

Апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен вәкаләтле булган органнар тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы документларга апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте, ГХАТ органнары) тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып физик һәм юридик затлар тора.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә Идарә үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Апостиль кую.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе (алга таба – Идарә).

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Идарәнең мәгълүмат ресурслары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү бүлеге (алга таба – Бүлек).

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) Регламентка 1 нче кушымтадагы үрнәк буенча апостиль кую;

2) Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестрын алып баруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – ГХАТ БДР) реестр язуы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү (Регламентка 4 нче кушымта).

Апостиль аерым кәгазь битенә куела (Регламентка 1 нче кушымта) һәм теләсә нинди төстәге җеп белән тегелгән килеш документ белән беркетелә. Беркетелгән урында документның соңгы бите тыгыз кәгазь белән «йолдызчык» итеп ябыштырыла, аңа мөһер сугыла. Мөһер эзе «йолдызчык»ка тигез урнашырга тиеш. Беркетелгән битләрнең саны Бүлек җитәкчесенең имзасы белән раслана.

Апостильдә документны имзалаган затның фамилиясе һәм инициаллары, документны биргән учреждениенең рәсми атамасы күрсәтелә, таныклаучы органның урыны (шәһәре), дата, затның фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы, апостильнең номеры күрсәтелә, мөһер һәм таныклаган затның имзасы белән беркетелә.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе ГХАТ БДР теркәлә.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән;

мөрәҗәгать итүчегә ул күрсәткән адрес буенча почта аша.

Дәүләт хезмәтен кәгазьдә күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать итүче Идарәгә мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәреп яисә шәхсән тапшырылган булса, дәүләт хезмәте Идарә тарафыннан гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң биш эш көненнән артмаган чорда күрсәтелә.

Әлеге чор документны биргән ГХАТ органы адресына яисә гражданлык хәле акты язуы саклана торган ГХАТ органы адресына документны имзалаган вазыйфаи зат имзасының үрнәген, мөһер эзен һәм аның вәкаләтләре турындагы мәгълүматны, шулай ук гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алу фактының булуы яки булмавы турында Идарә тарафыннан гариза җибәрү зарурлыгы килеп туган очракта, 30 эш көненә кадәр арттырылырга мөмкин.

Әлеге карарны кабул итү чорын арттыру турында Идарә мөрәҗәгать итүчегә Идарәгә гариза килгән көннән алып бер эш көне эчендә хәбәр итә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Идарәнең рәсми сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) (техник мөмкинлек булган очракта) түбәндәгеләр урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Идарәнең, дәүләт хезмәте күрсәтә торган Идарәдәге вазыйфаи затның, дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге:

а) билгеләнгән форма буенча кәгазь чыганактагы документ рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (Регламентка 2 нче кушымта);

б) Татарстан Республикасы ГХАТ органы тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актын дәүләт теркәве турында документ;

в) мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ (Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында бирелә);

г) юридик затның вәкаләтләрен раслаучы документ, әгәр мөрәҗәгать итүче сыйфатында юридик зат эш итсә (ышаныч кәгазе яки башка документ);

д) салым ташламалары бирү өчен нигез булып торган документ.

2.6.2. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының формасы Идарәнең рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.3. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.6.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Идарә тарафыннан түләүченең дәүләт пошлинасын түләү фактын раслаучы белешмәләр соратыла.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт пошлинасын түләү фактын раслаучы документларны үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон формада да.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган исемлеген тапшыру;

б) Россия Федерациясенең башка субъекты территориясендәге ГХАТ органы тарафыннан бирелгән документны тапшыру;

в) Гаага конвенциясендә катнашмаган дәүләтнең компетентлы органнарына күрсәтү өчен билгеләнгән документны тапшыру;

г) Россия Федерациясе белән шартнамәсе (килешүе) булган дәүләттә документларны легальләштерүнең теләсә нинди төрен таләп итүне гамәлдән чыгаручы документ тапшыру;

д) дипломатик вәкиллекләр һәм консуллык учреждениеләре тарафыннан башкарылган документны тапшыру;

е) чит ил дәүләтенең органы, вазыйфаи затыннан алына торган документны тәкъдим итү;

ж) вазыйфаи затның имзасы һәм (яки) ГХАТ органыныж мөһере/штамп эзе булмаган документны тәкъдим итү;

з) төзәтмәләре, өстәп язылган, чистартылган урыннары булган, ГХАТ органының герблы мөһер эзе укылмый торган документны тәкъдим итү.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

а) имзалау вәкаләте булмаган зат тарафыннан имзаланган документны тапшыру;

б) затның имзасы һәм (яки) мөһер эзләре Идарәдә булган үрнәкләргә туры килмәгән документны тәкъдим итү;

в) затның имзасы һәм (яки) мөһер эзләре Идарәдә әлеге документ чыккан ГХАТ органында имзаларның һәм (яки) мөһер эзләренең үрнәкләре булмау сәбәпле, Идарә тарафыннан таныклана алмый торган документның тәкъдим ителүе;

г) мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән күләмдә дәүләт пошлинасының түләнмәве.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

2.9.1. Апостиль куйган өчен һәр документка 2500 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләнә.

Апостиль кую өчен мөрәҗәгать иткәндә дәүләт пошлинасы мөрәҗәгать итүче тарафыннан апостиль куйганчыга кадәр түләнә.

2.9.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы өчен түләү Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 статьясының 1 пунктындагы 48 пунктчасы нигезендә кредит учреждениеләре (банклар) яки Республика порталы (техник мөмкинлек булган очракта) аша түләнә.

Дәүләт пошлинасын күчерү өчен кирәкле реквизитлар белән квитанция бланкын мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Бүлек белгеченнән яки Идарәнең рәсми сайтыннан алырга мөмкин.

2.9.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы түләүдән азат ителә торган затлар исемлеге Россия Федерациясе Салым кодексының 333.35 статьясында билгеләнгән.

Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә таләп ителә торган, шулай ук Россия Федерациясенең дипломатик вәкиллекләре һәм консуллык учреждениеләре гаризалары буенча гражданлык хәле актларын теркәү турындагы документларга апостиль куйган өчен дәүләт пошлинасы түләнми.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен башка төрле түләү алынмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, Идарә һәм (яки) вазыйфаи зат гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтү өчен җибәрелгән документка үзгәрешләр керткән очракта, мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләр өчен алдан язылу мөмкинлеге бирелә, ул Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) гамәлгә ашырыла.

Алдан язылу буенча гариза тапшырганда чират көтүнең максималь чоры алдан язылу буенча билгеләнгән вакытны 5 минуттан да күбрәккә арттырып җибәрә алмый.

Кабул итү буенча билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач мөрәҗәгать итүче килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылу буенча мөрәҗәгать итүчеләр булмаган очракта, мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү чират тәртибендә башкарыла.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта яисә почта аша җибәргәндә, гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз үтеп керә алу максатларында, түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

2) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итә алу үзлеге бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларга, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, тоткарлыксыз хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен кирәкле җайланмаларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;

6) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү;

7) хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.12.3. Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Идарәнең рәсми сайтында, Бердәм порталда һәм Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан ярдәм күрсәтү;

дәүләт пошлинасын Республика порталында түләү мөмкинлеге (техник мөмкинлек булганда);

Республика порталында алдан язылу мөмкинлеге (техник мөмкинлек булганда).

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

3) Идарә белгечләренең Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә багланышка керү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче бүлеккә үзе, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать иткәндә алынырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

КФҮләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелергә мөмкин.

2.14.3. Дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми.

2.14.4. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм реестр язуларында бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү өчен вариантлар исемлеге, шул исәптән мондый дубликатны бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликатын бирү гамәлгә ашырылмый.

3.3. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча юллау административ процедурасын тасвирлау

Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча җибәрү гамәлгә ашырылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) техник хаталарны төзәтү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта ярдәмендә (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булганда Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультацияләү, тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.6. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче яисә ул вәкаләт биргән зат гаризаны Идарәгә шәхсән яисә заказлы почта юлламасы итеп тапшыра ала.

Почта аша заказлы почта юлламасы рәвешендә тапшырылган гариза гомуми тәртиптә карала.

3.6.1.1. Бүлек белгече:

тапшырылган документларның комплектлылыгын Регламентның 2.6 пункты таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерә;

гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турындагы документларны рәсмиләштерүнең дөреслеге буенча (тапшырылган документларның форма һәм эчтәлеге буенча билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә, документларда кирәкле имзаларның, мөһерләрнең, реквизитларның булуын тикшерә, чистартылган, төзәтелгән урыннар булмавын) тикшерә.

3.6.1.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки вәкаләтле зат аша мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында хәбәр итә һәм, баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кайтарып бирә. Таләп буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Гариза белән документлар почта аша җибәрелгәндә, Бүлек белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта аша җибәрә.

3.6.1.3. Бүлек белгече, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, гаризаны һәм документларны Идарәнең Эшчәнлек күрсәтмәсендә билгеләнгән тәртиптә терки һәм, карап тикшерү өчен кабул итә.

3.6.1.4. Мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итү факты һәм датасы билгеләнгән формада (Регламентка 3 нче кушымта) гаризаны һәм документларны кабул итү турында белдерү белән раслана.

Регламентның 3.6.1-3.6.1.4 пунктларында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар Идарәгә алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.7. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.7.1. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.7.2. Бүлек белгече ГХАТ БДР функционалы ярдәмендә Дәүләт һәм муниципаль түләүләр дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – ДМТ ДМС) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасының түләнгән булуына раслама булуын тикшерә.

3.7.3. ДМТ ДМС системасында дәүләт пошлинасын түләү факты расланмаса яисә Дәүләт һәм муниципаль түләүләр дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалану мөмкинлеге булмаса, Бүлек белгече программа-техника чараларын кулланып мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр бирү турында электрон формада гариза формалаштыра һәм ведомстоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) аша Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсенә җибәрә.

Әлеге органга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

3.7.4. Әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгать буенча әлеге документлар белән эш итүче орган тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.7.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек электрон формада ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда, соралган мәгълүматлар электрон формада булмау сәбәпле, кәгазь чыганакта башкарыла ала.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара гарызнамә алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Административ процедураның нәтиҗәсе: гаризага җавап яки мәгълүмат булмау турында белдерү.

3.7.6. Бүлек белгече ведомствоара электрон мәгълүмати хезмәттәшлек системасы аша сорала торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматны (белешмәләрне) яки мәгълүматның булмавы турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча белешмәләр алынган көнне үтәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында юлланган гаризалар, гаризага җавап алу яисә мәгълүматның булмавы турында белдерү.

Белешмәләрне кулланунның максатлары булып дәүләт пошлинасын түләүгә раслама, шулай ук мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.8.1. Бүлек белгече:

ГХАТ БДР кулланып, «Апостиль» штампын формалаштыра һәм аны кәгазь чыганакта бастыра. Техник мөмкинлек булмаган очракта, апостиль кую махсус «Апостиль» штампы тамгасын кулланып башкарыла, ул документ белән беркетелгән аерым биткә куела һәм аны түбәндәге тәртиптә тутыралар:

– апостильнең 1 пунктында – Россия Федерациясе;

– апостильнең 2 пунктында – апостиль кую өчен бирелгән документны имзалаган затның чыгыш килешендә фамилиясе, инициаллары;

– апостильнең 3 пунктында – рәсми документны имзалаган затның вазыйфасы;

– апостильнең 4 пунктында – Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле, документны мөһер эзе белән таныклаган органның рәсми исеме;

– апостильнең 5 пунктында урын-вакыт килешендә апостиль куела торган шәһәр күрсәтелә;

– апостильнең 6 пунктында – аны кую көне;

– апостильнең 7 пунктында – апостиль куйган затның чыгыш килешендәге фамилиясе һәм инициаллары, вазыйфасы, шулай ук таныклаган органның исеме;

– апостильнең 8 пунктында аның номеры күрсәтелә. ГХАТ БДР апостильгә тәртип саны беркетелә һәм тутырылган штамп формасы генерацияләнә;

апостильне аерым биттә чыгара, документ белән беркетә һәм имзалау һәм имзаны герблы мөһер эзе белән таныклау өчен Бүлек җитәкчесенә тапшыра;

Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән очракларда, Регламентка 4 нче кушымтадагы форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү проектын әзерли;

әзерләнгән документларны, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү проектын килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: апостиль куелырга тиешле документларның билгеләнгән критерийларга туры килүен бәяләү, документларга апостиль кую, килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрелгән документларның проектлары.

3.8.2. Бүлек җитәкчесе:

апостильне имзалый (апостильнең 10 пункты), үзенең имзасы белән тегелгән, саннар сугылган һәм рәсми документта беркетелгән битләр санын таныклый, апостильгә һәм кәгазь «йолдызчык» урынында (апостильнең 9 пункты) герблы мөһер эзе калдыра. Кәгазь «йолдызчык» урынында куела торган герблы мөһер эзе «йолдызчык»ка һәм кәгазьгә тигез ятарга тиеш. Апостильнең 9 пунктында герблы мөһер эзен сукканда эзнең апостиль кысаларыннан чыгуы рөхсәт ителә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында мотивацияле белдерү проектын тикшерә һәм аны, килештерү өчен, Идарә җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура әлеге документлар Бүлек җитәкчесенә килештерү өчен алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган апостиль штампы яки Идарә җитәкчесенә килештерү өчен җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү проекты.

3.8.3. Идарә җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында мотивацияле белдерүне имзалый һәм аларны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.8.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү.

3.8.4. Бүлек белгече куелган апостиль белән документны документлар бирү журналында терки яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү реквизитларын ГХАТ БДР кертә.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып документка апостиль кую яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү рәсмиләштерү тора.

3.8.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры документны биргән ГХАТ органы адресына яисә гражданлык хәле акты язуы саклана торган ГХАТ органы адресына документны имзалаган вазыйфаи зат имзасының үрнәген, мөһер эзен һәм аның вәкаләтләре турындагы мәгълүматны, шулай ук гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алу фактының булуы яки булмавы турында гариза җибәрү зарурлыгы килеп туган очракта 30 эш көненә кадәр арттырылырга мөмкин.

Апостиль кую вакыты арттырылган очракта Идарә бу хакта апостиль кую вакытын арттыру турында карар кабул ителгән көннән башлап бер эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.9.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура апостильгә кул куелган яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр ителгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.9.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен Идарәгә мөрәҗәгать иткән очракта, Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта аша) апостиль куелган документны яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерүне бирә (юллый).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гаризада апостиль куелган документны яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерүне тапшыру ысулы буларак почта аша күрсәтелгән очракта – апостиль куелганнан соң яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү бер эш көне эчендә җибәрелә;

гаризада апостиль куелган документны яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерүне бирү ысулын шәхсән күрсәткән очракта – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: апостиль куелган, бирелгән (җибәрелгән) документ яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү.

3.10. Техник хаталарны төзәтү

3.10.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

ирекле формада төзелгән техник хатаны төзәтү турында гариза (тәкъдим ителгән формасы Регламентка 5 нче кушымтада китерелгән);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мәгълүматларындагы техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша җибәрелә.

3.10.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар Идарәгә килгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән документлар белән гариза.

3.10.3. Апостильне яңадан рәсмиләштерү яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү максатында Бүлек белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны һәм аңа теркәп тапшырылган документларны карый;

апостильне яңадан рәсмиләштерә яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итә;

яңадан рәсмиләштерелгән апостильне имзалауга яки әзерләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү проектын килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.10.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесенә җибәрелгән, үзгәртеп рәсмиләштерелгән апостиль яки апостиль куюдан баш тарту турында мотивацияле белдерү.

3.10.4. Бүлек җитәкчесе:

яңадан рәсмиләштерелгән апостильгә кул куя яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерүне килештерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында килештерелгән белдерүне Идарә җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.10.3 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: яңадан рәсмиләштерелгән апостиль яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында Идарә җитәкчесенә юлланган белдерү.

3.10.5. Идарә җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы белдерүне имзалый һәм аны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.10.4 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү.

3.10.6. Бүлек белгече, техник хатаны төзәтү турындагы гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, апостильнең яңадан рәсмиләштерелүе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Идарә белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерүгә кул куелган көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә апостильне яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итү яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.10.7. Бүлек белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта аша) яңадан рәсмиләштерелгән апостиль яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү бирүне гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризада яңадан рәсмиләштерелгән апостильне яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерүне бирү ысулы буларак почта аша күрсәтелгән очракта – апостиль яңадан рәсмиләштерелгәннән соң һәм теркәлгәннән соң яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә;

техник хатаны төзәтү турындагы гаризада яңадан рәсмиләштерелгән апостильне яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерүне бирү ысулы буларак шәхсән күрсәтелгән очракта – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: яңадан рәсмиләштерелгән апостиль белән бирелгән (җибәрелгән) документ яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе

4.1.1. Идарәдәге вазыйфаи затларның Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Бүлек җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.1.2. Агымдагы контрольлек Идарәдәге вазыйфаи затларның Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм аларның ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контрольлек тәртибе һәм формалары

4.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Идарәдәге вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылышына, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлешенә;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүенә.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарәнең вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контроль тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Идарә эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә, Идарәнең вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Идарәгә шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә Идарә җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарлар һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый

актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Идарәнең, Идарәдәге вазыйфаи затның, дәүләт граждан хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Идарәнең рәсми сайтын, Бердәм порталны, Республика порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

5.4. Шикаять теркәлгәннән соң 15 эш көне эчендә каралырга тиеш. Идарәнең, Идарә вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – мөрәҗәгать аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә карала.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Идарәнең, Идарәдәге вазыйфаи затның яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең исеме, урнашкан урыны турында белешмә, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә мөмкин булган элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) яисә почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Идарәнең, Идарәнең вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең Идарәнең, Идарәнең вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, Мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Апостиль кую буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Апостиль куелган аерым битне таныклый торган документка тегеп кую үрнәге

Беренче ягы

A P O S T I L L E * А П О С Т И Л Ь
(CONVENTION DE LA HAYE DU 5 OCTOBRE 1961-
ГААГА КОНВЕНЦИЯСЕ, 5 ОКТЯБРЬ, 1961 ЕЛ)

1. Россия Федерациясе
Әлеге рәсми документ
2. Имзаланды ______________________________
(фамилия)
3. Түбәндәге буларак эш итә ______________________________
______________________________
(вазыйфа)
4. Мөһер/штамп белән беркетелде ______________________________
______________________________
(учреждение исеме)

Т А Н Ы К Л А Н Д Ы

5. Шәһәр ______________ 6. ________________
(датаны саннар белән)
7. ______________________________

______________________________
(таныклык бирү органы исеме)
8. №
9. Мөһер/штамп 10. Имза
____________________ ____________________

**Икенче ягы**

Мөһер
Барлыгы номерланды, тегелде
һәм мөһер белән беркетелде__________ бит

______________________________

(дата һәм апостиль куйган затның имзасы)

Апостиль кую буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

______________________________
(ГХАТ органы исеме)
______________________________

______________________________
(Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме,
атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
______________________________
(шәхесне раслаучы документ исеме)
сериясе__________ № ______________________

______________________________
(документны биргән орган атамасы)
______________________________
(бирү датасы)
______________________________
(яшәү урыны)
______________________________

______________________________
(мөрәҗәгать итүчегә җибәрү өчен адрес)
______________________________

______________________________
(мөрәҗәгать итүченең элемтә телефоны)

« ____________________»
(билгеләү датасы)

Гариза № _______

____________________________________ тапшырылырга тиешле, әлеге документларга апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында үтенәм:

| № | Гражданлык хәле актының төре | Документның сериясе, номеры | Документны бирү датасы | Документны биргән ГХАТ органының исеме | Документ бирелгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Акт язуын теркәү номеры һәм датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |

«____»___________ 20__ ел.

___________ ______________________________________________________________________
(имза) (мөрәҗәгать итүче –физик затның яисә юридик зат вәкиленең тулысынча ФИА (соңгысы – булган очракта))

Апостиль кую буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Документларны кабул итү турында № ____ белдерү

Мөрәҗәгать итүче ___________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме)

апостиль кую өчен түбәндәге документлар кабул ителде:

1.________________________________________________________________

2.________________________________________________________________

3.________________________________________________________________

4.________________________________________________________________

5.________________________________________________________________

6.________________________________________________________________

7.________________________________________________________________

8.________________________________________________________________

Белдерү биргән ГХАТ органының исеме: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе

Документлар кабул ителде: ___________________ Бирү датасы: ___________ ______________

Документларны кабул иткән вазыйфаи зат ________________ _____________________
(имза) (тулы имза)

Апостиль кую буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ГХАТ идарәсе документларны тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта:

_______________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

_______________________________________________

документның исеме)

Түбәндәге нигезләр буенча: ______________________

_______________________________________________.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты ГХАТ
идарәсе җитәкчесе ________ / ______________________

имза фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

«___»____________ 20___ ел.

Мөһер урыны (булган очракта)

Апостиль кую буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинеты ГХАТ идарәсенә
кемнән ________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адресы:
________________________________________
шәхесне раслаучы документы
сериясе __________ № ________________
бирелгән ____________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

_____________________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтү турында бирелгән документ)
апостиль куйганда җибәрелгән техник хата турында хәбәр итәм.

Күрсәтелгән: ___________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:
_____________________________________________________________________________________.
Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.
Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
Документның әзер булуы турында миңа түбәндәгечә хәбәр итүегез турында үтенәм
______________________________________________________________________.
(хәбәр итү ысулы)

_______________ (дата) ___________ (имза) (______________________________) (тулы имза)

Апостиль кую буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
(белешмәлек) кушымта

Апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар, аны күрсәтүне контрольдә тотучы органнар һәм вазыйфаи затлар реквизитлары

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Идарә җитәкчесе | (843) 293-14-89 | Gulshat.Nigmatullina@tatar.ru |
| Идарә җитәкчесе урынбасары | (843) 293-01-57 | A.Renat@tatar.ru |
| Бүлек җитәкчесе | (843) 293-33-47 | Elvira.Minnegaleeva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | (843) 264-77-29 | pisma@tatar.ru |